**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында**

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указы басылып чыгу белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советын Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе дип үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясен, аның функцияләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенә йөкләп, кыскартырга.

4. Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегендә эшләп килүче коррупциягә каршы көрәшү комиссиясе (советы) атамасына һәм нигезләмәгә кирәкле үзгәрешләр кертергә;

тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе карарларын үтәү өчен кирәкле чаралар күрүне тәэмин итәргә.

6. 4 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Президенты указларының үз көчен югалтуын танырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

8. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү турында тәкъдимнәр кертергә, шулай ук аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

9. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 13 октябрь
№ ПУ-986

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «13» октябрендәге
ПУ-986 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турындагы нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы даими гамәлдә булган координация органы булып тора.

2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук Комиссия турындагы әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Президентының Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча идарәсе белән берлектә гамәлгә ашыра.

4. Комиссия аларга карата федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башкалар каралмаган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт урынында тәртипкә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә йөкләнгән функцияләрне башкара һәм тиешле мәсьәләләрне Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә карый.

II. Комиссиянең төп бурычлары

5. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы һәм аның президиумы карарларын үтәүне тәэмин итү;

б) коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү;

в) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының (алга таба - җирле

үзидарә органнары) коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча эшчәнлекләрен координацияләүне тәэмин итү;

г) Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү буенча чараларны тормышка ашыруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара килештерелгән гамәлләрен, шулай ук аларның федераль дәүләт органнарының территориаль органнары белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

д) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча гражданнар, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары, фәнни оешмалар белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

е) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы көрәшү буенча алып барылган эше турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү.

## III. Комиссиянең вәкаләтләре

6. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыра:

а) Татарстан Республикасы Президентына коррупциягә каршы көрәшү буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм Россия Федерациясе законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

б) коррупциягә каршы көрәшү буенча, шулай ук коррупция күренешләренә китерү мөмкинлеге булган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар эшли;

в) коррупция күренешләренә битараф кала алмау һәм үз-үзен тотышында коррупциягә каршы стандартлар формалаштыру максатларында гражданнар белән аңлату эшләре алып баруны оештыру буенча тәкъдимнәр әзерли;

г) түбәндәгеләрне оештыра:

коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын әзерләүне;

Татарстан Республикасының коррупциягә каршы көрәшү дәүләт программасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының коррупциягә каршы көрәшү программаларын эшләүне, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын, шул исәптән әлеге программаларда каралган коррупциягә каршы көрәшү чараларын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау аша да, контрольдә тотуны;

д) аларга карата федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башкалары каралмаган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның коррупциягә каршы көрәшү максатларында урнаштырылган тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәвенә кагылышлы мәсьәләләрне карый;

е) коррупция күренешләренә китерү мөмкинлеге булган, административ киртәләр тудыручы сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, аларны бетерү һәм киметү (шул исәптән гражданнар мөрәҗәгатьләре, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан белешмәләр, ризасызлыклар, гаризалар, федераль дәүләт органнары күрсәтмәләре нигезендә) буенча чаралар күрә;

ж) Татарстан Республикасының коррупциягә каршы көрәшү дәүләт программасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының коррупциягә каршы көрәшү программаларын тормышка ашыруга җәмәгатьчелек контролен көчәйтүгә булышлык итә;

з) коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә эшчәнлек турында еллык доклад (коррупциянең торышы һәм Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында җыелма хисап) әзерләүне, аны Татарстан Республикасы Президентының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны, массакүләм мәгълүмат чараларында бастыруны һәм федераль дәүләт органнарына җибәрүне (соратулар буенча) тәэмин итә.

## IV. Комиссияне формалаштыру тәртибе

7. Комиссия турындагы нигезләмә һәм Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

8. Комиссия составы Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретарь һәм Комиссия әгъзаларыннан формалаштырыла.

9. Комиссия рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты яисә вакытлыча аның вазыйфаларын башкаручы зат тора.

10. Комиссия составына коррупциягә каршы көрәшүдә катнашу аларның устав бурычлары булып торган Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары структур бүлекчәләре, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле аппараты бүлекчәсе, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, җәмәгатьчелек, шул исәптән фәнни һәм мәгариф оешмалары, җәмәгать берләшмәләре вәкилләре керергә мөмкин.

11. Комиссия әгъзасының үз вәкаләтләрен башка затка бирүе рөхсәт ителми.

12. Комиссия эшендә җәмәгать башлангычларында катнашалар.

13. Комиссия утырышларына федераль дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

14. Комиссия рәисе карары белән Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча эксперт бәяләмәсен анализлау, өйрәнү һәм әзерләү өчен вакытлыча яисә даими нигездә экспертлар җәлеп итәлергә мөмкин.

15. Комиссия карары белән 6 пунктның «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен Комиссия президиумы төзелә.

Комиссия президиумы составы Комиссия әгъзаларыннан төзелә һәм аңа Комиссия президиумы рәисе, Комиссия президиумы рәисе урынбасары, Комиссия президиумы секретаре һәм Комиссия президиумы әгъзалары керә.

## V. Комиссия эшчәнлеген һәм аның эш тәртибен оештыру

16. Комиссия эше план нигезендә һәм Комиссия тарафыннан раслanучы регламент нигезендә тормышка ашырыла.

17. Комиссия утырышларын Комиссия рәисе яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе урынбасары алып бара.

18. Комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, кварталга бер тапкыр уздырыла. Кирәк булганда, Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, шулай ук Комиссия әгъзасы инициативасы нигезендә Комиссия рәисе белән килештереп һәм Комиссия секретаре тәкъдиме буенча Комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

19. Комиссия утырышлары ачык (Комиссия әгъзасы булып тормаучы затларга да катнашу рөхсәт ителә) уздырыла. Тиешле мәсьәләләрне караганда, конфиденциальлекне тәэмин итү максатларында, Комиссия рәисе яисә ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары тарафыннан Комиссиянең ябык утырышын (бары тик Комиссия әгъзалары һәм утырышка чакырылучы затлар гына катнаша) уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин.

20. Комиссия карарлары утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Утырыш беркетмәсенә Комиссия секретаре кул куя һәм ул Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Комиссия карарлары Комиссия рәисе карары белән Комиссия әгъзалары арасында язмача сораштыру уздыру (читтән торып тавыш бирү) юлы белән дә кабул ителергә мөмкин.

21. Комиссия карарларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары чыгарылырга, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре бирелергә мөмкин.

22. Комиссия карары белән аерым мәсьәләләр буенча Комиссия әгъзаларыннан яисә алар вәкаләт биргән затлардан, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән һәм экспертлардан торган эш (эксперт) төркемнәре оештырылырга мөмкин.

23. Комиссия рәисе:

а) Комиссия эше белән гомуми җитәкчелек итә;

б) Комиссиянең эш планын (еллык планын) раслый;

в) Комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибен раслый;

г) үз вәкаләтләре чикләрендә Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

д) Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча федераль дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар белән эш иткәндә Комиссия вәкиле булып тора.

24. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итүне, Комиссия утырышларына материаллар әзерләүне һәм ул кабул иткән карарларның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тормышка ашыра.

25. Комиссия секретаре:

а) Комиссиянең эш планы (еллык планы) проектын әзерләүне тәэмин итә, аның утырышы көн тәртибен формалаштыра, Комиссия утырышына кирәкле материаллар, тиешле карарлар проектларын әзерләү буенча эшне координацияли;

б) Комиссия әгъзаларына, утырышка чакырылган затларга, экспертларга, башка затларга Комиссия утырышы уздыру урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат җибәрә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

в) Комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

г) Комиссия утырышлары нәтиҗәләре буенча Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтәүне оештыра.

26. Комиссия рәисе карары белән Комиссия карарлары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру өчен җибәрелергә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «13» октябрендәге
ПУ-986 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Комиссия рәисе |
| Камалтынов<br>Юрий Зимелевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Бәдретдинов<br>Марс Сарыйм улы | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы, Комиссия секретаре |
| Әмиров<br>Кафил Фәхразый улы | «Связьинвестнефтехим» ачык акционер җәмгыяте директорлар советы рәисе киңәшчесе, Казан милли тикшеренү технология университетының хокук белеме кафедрасы мөдире, философия фәннәре кандидаты (килешү буенча) |
| Белов<br>Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе |
| Бикеев<br>Игорь Измайлович | Икътисад, идарә һәм хокук институты (Казан шәһәре) беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры, Татарстан Республикасының «Граждан җәмгыяте» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты, профессор, юридик фәннәр докторы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Волкова<br>Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Гыйлаҗев<br>Илгиз Идрис улы | Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе (килешү буенча) |
| Глухова<br>Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Демидов<br>Алексей Иванович | Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Здунов<br>Артем Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Нәфиков<br>Илдус Сәед улы | Татарстан Республикасы Прокуроры (килешү буенча) |
| Николаев<br>Павел Михайлович | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сабурская<br>Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе |
| Сафиуллин Марат Әдип улы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Тимерҗанов Ринат Зәки улы | Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор (килешү буенча) |
| Фомин Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмитов Динар Газиз улы | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хохорин Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Хөснетдинов Фәрхәт Госман улы | Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе (килешү буенча) |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «13» октябрендәге
ПУ-986 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт урынында тәртипкә куелган таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) тарафыннан түбәндәгеләрне карау тәртибе билгеләнә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче түбәндәге затларның: Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарының, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарының, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министрының, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиленең, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесенең, Татарстан Республикасы министрының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасының, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасарының, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторының, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисенең, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасарының, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаренең (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат) хезмәт урынында тәртипкә куелган таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка карата чыгымнарны контрольдә тоту барышында алынган нәтиҗәләрне.

2. Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) Комиссия рәисенең түбәндәгеләргә нигезләнеп кабул иткән карары:

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә таянып уздырылган һәм Комиссиягә тапшырылган тикшерү материалларына;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның хезмәт урынындагы тәртипкә куелган таләпләрне үтәмәве турындагы Комиссия каравына тапшырылган башка материалларга;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка карата чыгымнарны контрольдә тоту турында карар кабул иткән затның чыгымнарны контрольдә тоту барышында алынган нәтиҗәләрне карап тикшерү турында Комиссиягә биргән тәкъдимнәренә;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның объектив сәбәпләр буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү мөмкин булмавы турында Идарәгә бирелгән гаризасы.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты исеменә язып, Идарәгә әлеге затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тапшырыла. Идарәдә гариза карап тикшерелә, аның нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә бирелә. Гариза, бәяләмә һәм башка материаллар гариза алынган көннән җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә бирелә.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү күздә тотылган Комиссия утырышын уздыру вакыты һәм аны уздыру урыны Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

5. Комиссия секретаре Комиссия утырышына куелачак мәсьәләләрне әзерләүне тәэмин итә, шулай ук Комиссия әгъзаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затларны Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, шулай ук утырышны уздыру вакыты һәм урыны турында утырышка кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итүне оештыра.

6. Әгәр Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан өчтән ике өлеше катнашса, ул гамәлгә хокуклы дип санала.

7. Карарлар кабул иткәндә Комиссиянең барлык әгъзалары тигез хокуклы була.

8. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының берсенә карата хезмәт урынында тәртипкә куелган таләпләрне үтәве яисә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы мәсьәлә каралса, Комиссиянең әлеге әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 13 - 15 пунктларында каралган карарны кабул иткәндә тавыш бирү хокукына ия булмый.

9. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа кагылышлы мәсьәлә каралучы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында нигезендә бирелә торган гаризада күрсәтә. Мондый күрсәтү булмаса, Комиссия утырышы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче заттан башка гына уздырыла.

10. Комиссия утырышына Комиссия рәисе карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, шулай ук кызыксынган органнар һәм оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин.

11. Комиссия утырышында Комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның аңлатмалары тыңлана һәм утырышның көн тәртибенә куелган мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карала. Комиссия утырышында Комиссия әгъзалары, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат үтенече буенча башка затлар күрсәтмәләре тыңланырга һәм алар тарафыннан бирелгән материаллар каралырга мөмкин.

12. Комиссия әгъзаларының һәм аның утырышында катнашкан затларның Комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокукы юк.

13. Материалларны карап тикшерү йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы «а» пунктчасының икенче һәм өченче абзацлары нигезендә Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) карап тикшерелә торган очракта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан хезмәт урынындагы тәртипкә куелган таләпләрнең үтәлмәве билгеләре юк дип табарга;

б) карап тикшерелә торган очракта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан хезмәт урынындагы тәртипкә куелган таләпләрнең үтәлмәве билгеләре бар дип табарга.

14. Тәкъдимне карап тикшерү йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы «а» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка

карата юридик җаваплылык чаралары куллану (яисә кулланмау) турындагы тәкъдим күрсәтелгән карар кабул ителә.

15. Гаризаны карап тикшерү йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирелмәү сәбәбен объектив һәм нигезле дип танырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирелмәү сәбәбен нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка әлеге белешмәләрне тапшыру чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирелмәү сәбәбен объектив түгел һәм әлеге мәгълүматларны бирүдән баш тарту ысулы булып тора дип танырга.

16. Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан административ хокук бозу билгеләре яки җинаять составы булган гамәлләр кылынуны (яисә кылынмауны) билгеләгән очракта, Комиссия секретаре Комиссия рәисе кушуы буенча әлеге гамәл кылу (кылмау) турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы документларны өч көн эчендә, ә кирәк булганда кичектергесез рәвештә хокук куллану органнарына җибәрә.

17. Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашкан әгъзалары тавышының гади күпчелеге белән коллегиаль рәвештә кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

18. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кул куя.

19. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашкан башка затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләрнең һәрберсен, аңа карата мәсьәлә тикшерелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп, формалаштыру;

в) Комиссия утырышын уздыру өчен нигез биргән мәгълүмат чыганагы һәм аның Идарәгә бирелү датасы;

г) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм башка затларның карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышының кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) Комиссия карары һәм аны кабул итүне нигезләү.

20. Кабул ителгән карардан риза булмаган Комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язмача бирергә хокуклы, ул мәҗбүри рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

21. Комиссия карарыннан күчермә аңа карата мәсьәлә карап тикшерелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка, шулай ук аны билгеләп куюга (сайлауга, раслауга) вәкаләтле вазыйфаи затка (Татарстан Республикасы дәүләт органына) Комиссия утырышыннан соң җиде көн эчендә җибәрелә.

22. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә ала.

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «13» октябрендәге
ПУ-986 номерлы Указына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының үз көчен югалткан указлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы турында» 2011 елның 21 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы.
2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы Указының 4 пункты.
3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указының 3 пункты.
4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге ПУ-1145 номерлы Указы.
5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» 2013 елның 20 мартындагы ПУ-241 номерлы Указы.
6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 12 сентябрендәге ПУ-894 номерлы Указы.
7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 18 октябрендәге ПУ-1030 номерлы Указы.
8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» Указына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 12 ноябрендәге ПУ-1108 номерлы Указы.
9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 18 мартындагы ПУ-284 номерлы Указы.

10. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү чаралары турында» 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы Указына кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 7 пункты.

11. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы составына һәм Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1055 номерлы Указының 1 пункты.

12. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 19 мартындагы ПУ-298 номерлы Указының 2 пункты.